СОВЕТ **Азевского сельского поселения** **Агрызского муниципального района** **Республики Татарстан**	**Татарстан Республикасы** **Әгерҗе муниципаль районы** **Азево авыл җирлеге** **СОВЕТЫ**

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

27.04.2026 Азево авылы № 10-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 26 ноябрендәге 54-1 номерлы Азево авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 26 ноябрендәге 54-1 номерлы Азево авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 8 өлешендәге 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнгән тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;»;

8 статьяның 3 өлешендә «һәм күрсәтелгән законнар (карарлар) белән расланган чыгымнарның гомуми күләменең 3 процентыннан арта алмый» сүзләрен төшереп калдырырга;

19 статьяның 2, 10 өлешендәге 1.3 пунктын төшереп калдырырга;

30 статьяның 5, 8 өлешендәге 1.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.5. 20 статьяны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Е.В.Афанасьев